Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Колыш авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«13» ноябрь, 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 45,69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлегенең 29.10.2019 ел 49/2 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары нигезендә Боерган авыл җирлеге Колыш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2026 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Колыш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең)сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

-урамнарны яктырту җайланмасы(СИП сузу, Колыш авылында яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)ны хәл итү.”

2. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Колыш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Колыш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты
Җитәкчесе Г.Г.Минакова